

Коз – туйлар вакыты. Кvп гасырлык гореф-гадәтләр буенча татарларда туйлар вакыты – коз, бигрәк ноябрь ае.
Узган жомгада vз халкынын гореф-гадәтләрен, йолаларын vтәп, Торбеево районы Татар Юнәсе авылында яшәvче Ринат Утешев кvрше Атюрьево районынын Усть-Рахмановка авылы кызы Алсу Карабашева белән никахлашты. Һәр никахлашучы пар туганнары, дуслары очен бу коннен кабатланмас истәлек булып калуын тели; шулай булды да. Гашыйк парнын тормышындагы моһим вакыйгалары матур һәм якты vтте; этник vзенчәлеккә бай булды.
Моселман яшь гаилә очен уртак тормышнын менә дигән башлангычы-йорәкләрнен бай мәдәни мираска һәм милләтнен тарихи хәтеренә кагылуы.      Тантананын искиткеч матурлыгына һәм уникальлегенә Торбеево ит һәм сот промышленносте колледжы стеналарында студентларнын гvзәл һәм романтик яшьлегендә язмышчан танышу булды. Яшьләр яучылык, ярәшv һәм сатып алу ритуалларынын топ геройлары булдылар. Ныклы гаилә жепләренен, бер - берсенә карата vзара хормәтнен нигезе булып, изге вәгъдәләр белән ныгытылган гадәт - никахлашу аерым мәгънәгә ия. Никахлашу йолысы истәлекле итеп vтте. Банкет залы шулай ук Аллаһы Тәгалә индергән Коръән сvрәләре белән бизәлгән иде. Элегант кияv белән яшь киленнен пар аккошлар сыман акрын биюләре сокландыргыч иде, гvя тын дингездә йозделәр; аларнын кvзләре мәхәббәт уты белән балкыды. Тыйнаклык, тәрбиялелек, белемлелек, хезмәт союченлекне vз эченә алган Ринат белән Алсу яшьтәшләре очен һәрвакыт унай vрнәк һәм әти-әниләр очен горурлык булып торалар.
Якты, кызыклы һәм истә калырлык туй чын мәгънәсендә кин кvнеллелек, жылы аралашу атмосферасы, эчкерсез кvнел ачу, купшылык һәм кин колачлыгы белән тан калдырды.
Борынгы ислам ышанычлары буенча, кознен сонгы аенда тозелгән никах ир белән хатынга муллык һәм иминлек вәгъдә итә, ә мондый истәлекле кондә явым-тошем озак һәм бәхетле гаилә тормышынын яхшы билгесе булып тора. Нәкъ менә шундый, милли стильдә башкарылган туй борынгы гореф-галәтнен эстетикасын һәм тынычлыгын

тулырак чагылдыра.
Бу татар - мишәрләрнен яшь буыны Мордовиядә яшәргә һәм эшләргә ниятли. Беренче адымны ООО «МПК «Атяшевский»га эшкә урнашып, Ринат хезмәт биографиясен башлап жибәрде.
Алар, торыр урын итеп, 1869 елдан башлап vз елъязмасын алып баручы гаилә башлыгынын кече ватанын сайларлар, могаен. Икенче торле әйткәндә - Татар Юнәсен. Туган якларына мондый тугрылыкны алар бик гади анлаталар: «Ул безгә бик кадерле һәм матур! Биредә кешеләрнен ин яхшы сыйфатларын, планнарын һәм ниятләрен тормышка ашыру очен барысы да бар. Бәхет очен тагын нәрсә кирәк сон?» Һәм бу сvзләргә боек зирәклек салынган. Жәмгыятьнен яна ячейкасы Татар Юнәсе авылы очен дә яхшы билге ул, димәк, ул алга таба да яшәячәк һәм vсәчәк дигән сvз.

**Н.Хәлил**